БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 12 2020 ел № 374

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законының үз көчен югалтуын тану хакында» 2020 елның 19 ноябрендәге 75 - ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 76 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2020 елның 11 маендагы 169 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 18. 12
374 номерлы карарына
кушымта

**Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар**
**ИСЕМЛЕГЕ**

| Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы статьялары | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1. статьясы**<br>Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (ТР дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының, предприятиенең, учреждениенең, башка оешманың элмә тактасында үз исеме турында белешмәне һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматларны күрсәткәндә телләр турында ТР законнарын бозуга карата) | - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы.<br>- Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы.<br>- Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор). |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.4. статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.5. статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.6. статьясы**<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.7. статьясы**<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын файдалану | - Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы,<br>- Балтач район башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы. |

| | |
|---|---|
| тәртибен бозу | |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.8. статьясы**<br>Сату һәм (яисә) реализацияләү максатларында өй шартларында этил спиртлы продукция җитештерү<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2. статьясы**<br>Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1. статьясы**<br>Билетсыз йөрү<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.2. статьясы**<br>Багаж йөртү кагыйдәләрен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.6. статьясы**<br>Пассажирны йөртүдән баш тарту | - Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.15. статьясы 2 өлеше**<br>Террорчылыкны профилактикалау, аның чагылышларыннан килгән зыяннарны минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль орган карарларын үтәмәү яисә бозу | - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе<br>- Балтач район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.12. статьясы**<br>Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.13. статьясы**<br>Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм исәпне алып бару тәртибен бозу | - Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары.<br>- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары.<br>- Балтач район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе.<br>- Балтач район Советының оештыру бүлеге башлыгы. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан** | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының әйдәп |

| | |
|---|---|
| **Республикасы кодексының 2.17 статьясы**<br>Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуын булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | баручы белгече. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.3 статьясы**<br>Җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.4. статьясы**<br>Урамны, квартал эчен яктыртуны карап тоту кагыйдәләрен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.5 статьясы**<br>Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6. статьясы**<br>Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.7. статьясы**<br>Этләрне урамда йөртү тәртибен бозу | - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор). |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.8. статьясы**<br>Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14. статьясы**<br>Мәдәни-тамаша чараларында булганда иҗтимагый тәртипне бозу<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.15. статьясы**<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлегенең баш белгече. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.10. статьясы (Гражданнарга** | - Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы. |

| | |
|---|---|
| **карата)**<br>Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозу | - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор). |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.11. статьясы**<br>Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итү таләпләрен үтәмәү | - Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы;<br>- Балтач район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторының баш белгече.<br>- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының әйдәп баручы белгече. |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.16. статьясы**<br>Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырган өчен түләмәү<br>**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.17. статьясы**<br>Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт янындагы территориядә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру | - Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор);<br>- Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече; |
| **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 4.4. статьясы**<br>Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу | - Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары (баш архитектор);<br>- Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе. |
| **Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4. статьясы 1 өлеше**<br>Дәүләт күзәтчелеген (контролен) гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи затының, федераль законнар нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешманың вазыйфаи | - Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (инфраструктура үсеше буенча);<br>- Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе.<br>- Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм |

| | |
|---|---|
| затының, муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы органның вазыйфаи затының законлы күрсәтмәсенә буйсынмау<br><br>**Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4.1. статьясы 1 өлеше**<br>Дәүләт контроле (күзәтчелеге)органы вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулау<br><br>**Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5. статьясы 1 өлеше**<br>Дәүләт күзәтчелеген (контролен), муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган (вазыйфаи зат) тарафыннан билгеләнгән вакытка закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең (карарларның, күрсәтмәләрнең, карарларның) үтәлмәве<br><br>**Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.7. статьясы**<br>Дәүләт органына (вазыйфаи затка), дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органга (вазыйфаи затка), федераль законнар нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешмага (вазыйфаи затка), муниципаль контрольне, муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органга (вазыйфаи затка) законда каралган һәм әлеге орган (вазыйфаи зат) тарафыннан аның законлы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәк булган белешмәләрне (мәгълүматны) үз вакытында тапшырмау яисә вакытында тапшырмау яки дәүләт органына (вазыйфаи затка), дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органга (вазыйфаи затка), федераль законнар нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешмага (вазыйфаи затка), муниципаль контрольне, муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органга (вазыйфаи затка) мондый белешмәләрне (мәгълүматны) тулы булмаган күләмдә яки хаталы итеп тапшыру, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.16 статьясында, | торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы; |

| | |
|---|---|
| 6.31 статьясының 2 өлешендә, 8.28.1. статьясының 1, 2 һәм 4 өлешләрендә, 8.32.1 статьясында, 8.49 статьясының 1 өлешендә, 14.5 статьясының 5 өлешендә, 6.31 статьясының 2 өлешендә, 14.28 статьясының 4 өлешендә, 14.46.2 статьясының 1 өлешендә, 19.7.1, 19.7.2, 19.7.2-1, 19.7.3, 19.7.5, 19.7.5-1, 19.7.5-2, 19.7.7,19.7.8, 19.7.9, 19.7.12, 19.7.13, 19.7.14, 19.8, 19.8.3 статьяларында каралган очраклардан тыш. | |